**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Нырья авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**2021 елның 12 ноябре** **№ 6**

**«Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Иске Кенә-Юмья авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2021 елның 25 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Иске Кенә-Юмья авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Нырья авылы, Комсомол урамы, 69 йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.
2. 2021 елның 25 ноябренә 11 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Иске Кенә-Юмья авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Нырья авылы, Комсомол урамы, 69 йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.
3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Иске Кенә-Юмья авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 800 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Иске Кенә-Юмья авылының Московская урамында юлга вак таш

җәю; проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Иске Кенә-Юмья авылында өч җәяүлеләр күперен төзекләндерү һәм карап тоту; проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру?

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Нырья авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Нырья авыл җирлеге башлыгы В.В. Васильев